**Республика Татарстан**
**Глава**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы**

ул. Советская, д. 32 г, село Верхнее Стярле, Азнакаевский район, 423314

Совет урамы,32 г йорт, Югары Стәрле авылы, Азнакай районы, 423314

Тел. (факс) 8(85592) 42-6-18; e-mail: VSt.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2023 №1

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Чубар Абдулл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл Советының 2012 елның 21 апрелендәге 139 номерлы карары белән кабул ителгән авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында» гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен халык алдында тыңлаулар үткәрү максатыннын карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең 2022 елгы бюджеты үтәлеше турында"гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Халык алдында ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы - Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы.
3. Билгеләргә:
- үткәрү вакыты-2023 елның 10 апреле 10.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны- Югары Стәрле авылы мәдәният йорты:
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә торган адрес: 423314 ТР, Азнакай районы, Югары Стәрле авылы, Совет урамы, 32г нче йорт.
4. Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге башкарма комитетына:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының "2022 елда Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проекты буенча,

гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокта ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының "2022 елда Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проектын Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) веб-адресы буенча 2023 елның 16 мартыннын да сонга калмыйча урнаштырырга.
5. Әлеге карарны Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru ,Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru//. 2023 елның 16 мартыннан да соңга калмыйча игълан итәргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Башлык : Л.С.Сабирҗанова